| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2024 елның 3 сентябре № 19

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 елларның план чорына «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2023 елның 18 декабрендәге 44 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

«Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 19 декабрендәге 44 номерлы «2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

"2024 елга бюджетның төп характеристикаларын расларга:
1) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 27383346,36 сум күләмендә;
2) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 28436027,36 сум күләмендә.
3) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгы, аны каплауга 2024 елның 01 гыйнварына җирле бюджетның калган акчаларын җибәреп, 1052681 сум күләмендә.

2. 2024 елга «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. 2024 елга «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре күләмен әлеге Решениегә 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.
4. 2024 елга «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.
5. Бюджет ассигнованиеләрен «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетлары чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм

бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

6. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең 2024 елга максатчан статьялары (Лениногорск муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.
7. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Яңа Чыршылы поселогы., Заречная ур., 25 й., Үзәк ур., 12а й., Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
"Яңа Чыршылы авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

Р.Ә. Мөхәмәтшина